СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

11 декабрь 2018 ел г.Мензелинск № 11

**Советның 20.12.2005 елда кабул ителгән “Минзәлә муниципаль район Советы Башкарма комитетының “Мәдәният бүлеге” муниципаль учреждениесен булдыру турында”гы №9 карарына үзгәрешләр кертү турында**

08.10.2018 елда кабул ителгән “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты ведомствосында булган муниципаль казна учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль учреждениеләрнең уставына (положениеләр) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен җайга салучы, мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы булган хезмәт вазифаларын башкару барышында шәхси кызыксынучанык туу турында хәбәр итү вазифасы йөкләнүне билгеләүче тиешле учреждение (предприятие) җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре арасындагы хезмәт килешүләренә үзгәрешләр кертү турында”гы №1136 карары нигезендә, шулай ук 25.12.2008 елда кабул ителгән “Коррупциягә каршы тору” №273-ФЗ Федераль законы нигезендә, Минзәлә муниципаль район Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының “Мәдәният бүлеге” Муниципаль казна учреждениесе Положениесенә үзгәрешләр кертергә.

1.1. “Мәдәният бүлеге белән идарә итү” VI бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге 6.5 пунктын өстәргә: “Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу”.

2. “Мәдәният бүлеге” МКУ җитәкчесе Э.Н.Хәкимованы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының “Мәдәният бүлеге” Муниципаль казна учреждениесе Положениесенә үзгәрешләр кертүне уздыру буенча вәкаләтле дип билгеләргә.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының финанс-бюджет һәм җир-милек палатасына йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Салахов.